КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 март г.Казань № 190

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июнь, 374 нче карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 9 июнь, 374 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 сентябрь, 686 нчы; 2020 ел, 30 май, 441 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гариза бирүчедән кабул ителгән һәм хезмәт күрсәтүче органга җибәрелгән документларның скан-күчермәләре нигезендә формалаштырылган файлларны мөрәҗәгатькә «Кулга бирелде» статусы бирелгәннән соң алты ай узгач бетерү.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Система түбәндәге функциональ ярдәмче системалардан тора:

«Кулланучыларны авторизацияләү»;

«Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә гаризалар кабул итү процессы белән идарә итү»;

«Хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр арасында гаризаларны маршрутлаштыру»;

«Хезмәт күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан гариза эшкәртү процессы белән идарә итү»;

«Гаризаларның статуслары белән идарә итү»;

«Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен килештерү процессы белән идарә итү»;

«Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү процессы белән идарә итү»;

«Хисаплылыкны формалаштыру»;

«Администраторлаштыру»;

«Норматив-белешмә мәгълүмат»;

«Мөһер»;

«Тышкы мәгълүмат системалары белән үзара хезмәттәшлек итү»;

«Журналлаштыру»;

«Мәгълүмати иминлек»;

«Гариза бирүселәрнең электрон досьесын теркәү һәм саклау»;

«Мәгълүмат бирү»;

«Гражданнарның шалтыратуларын эшкәртү»;

«Татарстан Республикасының хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр порталы».».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин